ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«09» ноябрь 2021 ел №1204

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе турында нигезләмәне төзү һәм раслау хакында**

Торак-хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендәге мәсьәләләрне комплекслы карау, гражданнарның торакка хокукларын үтәү максатларында, Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты каршында Иҗтимагый торак комиссиясен төзергә.

2.Әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе турындагы нигезләмәне расларга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

3.1. торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен аларны торак урыннарына мохтаҗлар дип тану өчен нигезләре булган һәм (яисә) билгеләнгән тәртиптә аз керемлеләр дип танылган яки федераль закон, Россия Федерациясе Президенты Указы яисә Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән категориягә караган гражданнар кабул ителә;

3.2. гражданнарны исәпкә алу һәм теркәү, исәпкә алу һәм теркәү эшләрен оештыру; исәпкә алу эшләрен формалаштыру, законда билгеләнгән башка чараларны үтәү Арча район Советының 2015 елның 22 гыйнварындагы 318 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы башкарма комитеты вәкаләтләре өлешендә Арча муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитетына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр тапшыру турында килешү нигезендә, гамәлдәге законнарга туры

китереп, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.3. Исәпкә алу эшенең икенче нөсхәсе, гражданны (гаиләне) торак программаларында катнашучылар исемлекләренә кертү мәсьәләсен карау өчен, Арча муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә тапшырыла.

3.4. һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң максималь һәм минималь күләменең чик күрсәткечләрен билгеләү Татарстан Республикасы Арча район Советының юридик мәсьәләләр бүлеге тарафыннан ел саен бер тапкыр исәпләнә;

4.Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

- «Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Иҗтимагый торак комиссиясе төзү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2006 елның 12 гыйнварындагы 5 номерлы карарын;

- «Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 19 октябрендәге 959а номерлы карарын;

- «Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 06 августындагы 1261 номерлы карарын;

- «Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 30 декабрендәге1642 номерлы карарын;

- «Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 13 октябрендәге 1087 номерлы карарын;

- «Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 09 ноябрендәге 1115 номерлы карарын;

- «Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 31 гыйнварындагы 108 номерлы карарын;

- «Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 октябрендәге 1181 номерлы карарын;

- «Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 16 октябрендәге 980 номерлы карарын;

- «Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 06 мартындагы 130 номерлы карарын;

- «Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 декабрендәге 1038 номерлы карарын;

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р. Р. Мөхәрәмов

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
09.11. 2021 ел, №1204 карарына 1 нче
кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Мөхәрәмов Р.Р. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Галимуллин И.Ә. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Гатауллина С.С. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты аппаратының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары, комиссия секретаре. |
| ***Комиссия әгъзалары:*** | |
| Фазылов Р.Р. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты аппаратының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы; |
| Галимуллина Г.Х. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты аппаратының икътисад һәм финанслар бүлеге башлыгы; |
| Сәгыйтова Л.Г. | - Арча район Советы аппаратының юридик мәсьәләләр бүлеге башлыгы; |
| Яруллина Р.Г. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты аппаратының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы; |
| Габделгазизов И.Н. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты аппаратының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы; |
| Нигъмәтҗанова Г.Х. | - «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары, Арча шәһәр Советы рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Гатиятов Р. М. | - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Шакирова М.Н. | - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районында социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Сираҗиев И.Г. | - Арча муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе (килешү буенча); |
| Хәмидуллина Р.Ш. | - Арча район ветераннар (пенсионерлар) Советы рәисе (килешү буенча); |
| Мифтахетдинова Н.Р. | - Арча муниципаль районы Иҗтимагый Советы рәисе (килешү буенча); |
| Гатиятова Е.Н. | - Татарстан Республикасы Торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Арча җирле үзидарәсе төркеме җитәкчесе (килешү буенча). |

**Авыл җирлекләре башлыклары**

(документлар авыл җирлекләреннән кергән саен, килешү буенча чакырыла)

Апаз авыл җирлеге башлыгы

Кәче авыл җирлеге башлыгы

Наласа авыл җирлеге башлыгы

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы

Урта Аты авыл җирлеге башлыгы

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы

Утар Аты авыл җирлеге башлыгы

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы

Яңасала авыл җирлеге башлыгы

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы Башкарма
комитетының 09.11 2021ел,
№ 1204
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясе турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Иҗтимагый торак комиссиясе (алга таба - Комиссия) Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршында даими эшләүче коллегиаль орган булып тора, ул «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрнең торак хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләрне объектив, һәрьяклап карау максатында җирле үзидарә органнары вәкаләтләре нигезендә төзелә.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясенең башка хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Әлеге Нигезләмә Комиссиянең вәкаләтләрен һәм ул хәл итә торган мәсьәләләр даирәсен билгели.

## 2. Комиссиянең эш тәртибе

2.1.Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Комиссияне төзү һәм гамәлдән чыгару турында карар формасында карар кабул итә, шулай ук аның шәхси составын раслый.

2.2. Комиссия рәис, рәис урынбасары, җаваплы секретарь һәм Комиссия әгъзалары составында төзелә.

2.3. Килешү буенча Комиссия составына җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары, хезмәт коллективлары, профсоюзлар, ветераннар, яшьләр һәм башка иҗтимагый оешмалар вәкилләре керә ала, шулай ук граждан җәмгыяте институтлары вәкилләрен кертү рөхсәт ителә.

Комиссия рәисе:
- Комиссия эшенә гомуми җитәкчелек итә;
- утырышларны алып бара;
- кирәк булганда, Комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә;
- Комиссия карарларының үтәлешен тикшереп тора.

Комиссия рәисе урынбасары:
- Комиссия рәисенә үз вәкаләтләрен үтәүдә ярдәм күрсәтә;
- Комиссия рәисе булмаганда, аның функцияләрен үти.

Комиссия секретаре:
- Комиссия утырышларын уздыруны оештыра;
- Комиссиянең чираттагы яисә чираттан тыш утырышы турында Комиссия әгъзаларына хәбәр итә;

- Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара һәм рәсмиләштерә;

- Комиссиядә эшне алып бара;

- Кирәк булганда, Комиссия утырышлары беркетмәләреннән өземтәләр бирә яисә Комиссия беркетмәләренең күчермәләрен раслый.

Секретарь булмаганда, аның вазифаларын Арча муниципаль районы инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы башкара.

Комиссия әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

- Комиссия утырышларында көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча чыгыш ясарга;

- Комиссия кабул иткән карар белән килешмәгәндә, Комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә теркәлү узарга тиешле аерым фикерне язмача бәян итәргә.

2.4. Комиссия утырышлары кирәк саен, ләкин аена кимендә бер тапкыр үткәрелә.

Комиссия утырышында Комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса, Комиссия хокуклы дип санала. Һәр утырышта Комиссия секретаре тарафыннан беркетмә алып барыла. Беркетмәдә Комиссия исеме, утырыш датасы, беркетмәнең номеры, Комиссия утырышында катнашучыларның саны һәм исемлеге, көн тәртибе чагылдырылырга тиеш.

Беркетмәгә тикшерелә торган мәсьәләләрнең кыскача эчтәлеге, алар буенча кабул ителгән карар, кирәк булганда, Комиссия әгъзаларының конкрет мәсьәләләр буенча аерым фикере кертелә.

Комиссия карары утырышта катнашучылар саныннан гади күпчелек тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм беркетмәдә рәсмиләштерелә. Әгәр тавышлар саны тигез булса, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора. Комиссия карары утырышта катнашучы күпчелек әгъзалар тавыш биргәндә кабул ителгән дип санала.

Комиссия карарлары тәкъдим итү характерында.

2.5 Комиссия утырышы беркетмәсенә Комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм Комиссиянең барлык әгъзалары имза сала һәм Комиссия утырышы йомгаклары буенча Арча муниципаль районы башкарма комитетының хокукый акты кабул ителә.

- Программалар буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны җыелма исемлеккә кертү турында;

- дәүләт ярдәмен алучыларның исемлеген төзү;

- Программалар буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларның җыелма исемлеген раслау.

2.6. Исемлеккә кертү турындагы яисә кертүдән баш тарту турындагы карар Комиссиягә документлар тапшырылган көннән соң утыз эш көненнән дә соңга калмыйча гаризаны карау нәтиҗәләре буенча кабул ителергә тиеш. Карар кабул ителгән көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча тиешле гариза биргән гражданга мондый карарны кабул итүне раслый торган документ бирелә яисә җибәрелә.

2.7 Комиссия үз эшен ачык һәм намуслы итеп башкара, үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне вакытында карый һәм карарларын

беркетмәләрдә рәсмиләштерә.

2.8. Комиссиянең беркетмәсе (карарлары), шулай ук аларга кушып бирелгән материаллар документлар җирле үзидарә органнары, дәүләт органнары, хокук саклау органнары, материаллары комиссиягә һәм башка кызыксынучы затларга чыгарылган гражданнар өчен ачык һәм һәркем файдалана алырлык документ булып тора. Комиссия утырышлары беркетмәләре Комиссия секретаренда саклана һәм 5 ел узгач архивка тапшырыла.

2.9. Комиссия эшенә һәм кабул ителгән карарларга гаризалар, тәкъдимнәр һәм шикаятьләр Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан утыз көн эчендә «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2007 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының тиешле регламентларында каралган тәртиптә карала.

## 3. Комиссиянең төп бурычлары, функцияләре һәм хокуклары

3.1. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- муниципаль торак фондын исәпкә алу һәм бүлү мәсьәләләрендә җәмәгать контролен һәм хәбәрдарлыкны тәэмин итү;
- район территориясендә гражданнарның төрле федераль, республика торак программалары кысаларында гамәлгә ашырыла торган торак шартларын яхшыртуга хокукларын гамәлгә ашыру;
-Комиссия эшен, ачыклыгын, һәркем файдалана алырлык булуын камилләштерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр һәм чаралар әзерләү;
- торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган гражданнарның исәбен (реестрын) алып бару;

3.2. Комиссия компетенциясенә түбәндәге мәсьәләләр буенча гражданнар һәм оешмалар тарафыннан бирелә торган гаризаларны һәм документларны карау керә:

- гражданнар торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак танылган очракта, федераль яисә республика торак программаларында катнашучылар исемлегенә һәм ярдәмче программаларга кертү;
- гамәлдәге законнар нигезендә исәпкә кую турында карар кабул итү өчен гаризага кушымта итеп бирелгән документлар исемлегендәге документларның тулылыгын тикшерү;
- гражданнарны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбеннән алу турындагы мәсьәләләрне карау;
- торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу эшләренә үзгәрешләр кертү;
-гамәлдәге законнар нигезендә торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алынган гаиләләрнең локаль исемлекләрен төзүнең һәм алып баруның дөреслеген тикшереп тору;
- дәүләт ярдәмен алучыларның исемлеген булдыру һәм раслау;
- Программалар буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларның

җыелма исемлеген булдыру.

-тулай торакларда, хезмәт урыныннан бирелгән торак урыннарында, маневр фонды биналарында, халыкка социаль хезмәт күрсәтү системасы йортларында махсуслаштырылган торак урыннар бирү һәм алардан файдалану турында тәкъдимнәр әзерләү;

- торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнар исемлегендә торучы гариза бирүчеләрне еллык яңадан теркәү үткәрү.

3.3. Комиссиянең хокуклары:

- барлык программалар буенча исемлекләргә кертү өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнардан кирәкле документларны соратырга һәм алырга;

- торак мәсьәләләрен карау өчен дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, барлык милек рәвешләрендәге оешмалардан кирәкле белешмәләр, документлар һәм аңлатмалар соратырга һәм алырга;

- Комиссия утырышларына алардан кирәкле мәгълүматны һәм торак мәсьәләләрен караганда аңлатмалар алу өчен вазифаи затларны, белгечләрне һәм гражданнарны чакырырга;

- гамәлдәге торак законнарына каршы килә торган шартлар ачыкланганда, гражданнарга торак урыннары бирү турында күрсәтмәләр чыгаруны туктатып торырга.

- Комиссия бурычларыннан һәм вәкаләтләреннән килеп чыга торган башка гамәлләрне тормышка ашырырга.

## 4. Комиссия карарлары һәм аларны үтәү

4.1. Комиссия беркетмәләре, гражданнарның исәп эшләре, шулай ук аларга караган документлар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегендә саклана, анда аларны саклау өчен җаваплы зат булып Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары тора. Комиссия беркетмәләре архив эше турындагы законнар нигезендә саклана.

4.2. Комиссия карары утырышны уздыру һәм Комиссия беркетмәсен имзалаган көнне кабул ителгән дип санала.

4.3. Комиссия карарлары Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә, эзлеклелектә, шартларда һәм срокларда үтәлә.

## 5. Комиссиянең җаваплылыгы

5.1.Комиссия әгъзалары үз эшендә Россия Федерациясенең торак законнарына таянып эш итәргә, гражданнарның торакка хокукларын кысмаска һәм аларның законлы мәнфәгатьләрен якларга тиеш.

5.2.Комиссия әгъзалары Комиссия утырышында кабул ителгән карарларның Нигезләмә шартларына туры килүе/килмәве буенча уртак җаваплылыкта.

5.3.Әлеге Нигезләмәне бозган вазифаи затлар, хезмәткәрләр Россия

Федерациясе законнарында каралган тәртиптә җаваплы.

5.4 Әлеге Нигезләмә белән җайга салынмаган мөнәсәбәтләр гамәлдәге законнар нигезендә хәл ителергә тиеш.

Инфраструктура үсеше
бүлеге башлыгы Р.Р.Фазылов